| | | |
|---|---|---|
| БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАЛТАЧ РАЙОН<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«22» 02 2025 ел № 93

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы буенча 2025елнын I яртыеллыгына гомуми торак мәйданының бер квадрат метрының уртача бәясен раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 30 декабрендәге 1710 номерлы карары белән расланган «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем ала алырлык уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» Россия Федерациясе дәүләт программасының «Россия Федерациясе субъектларына торак һәм торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләүдә гражданнарга дәүләт ярдәме күрсәтү вәкаләтләрен гамәлгә ашыруда ярдәм итү» федераль проектын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 03 октябрендәге 888 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәт күрсәтүләре белән тәэмин итү» Татарстан Республикасы дәүләт программасының «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» төбәк проектын гамәлгә ашыру максатларында, «Татарстан Республикасы Бәяләүчеләр берлеге» эксперт-консультация советының «Бәяләр диапазонын билгеләү турында» 2025 елның 1 февралендәге 40 номерлы хаты һәм Балтач муниципаль районы торак комиссиясенең 2025 елның 21 февралендәге 3 номерлы карары нигезендә Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында 2020 - 2025 елларга яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программасын гамәлгә ашыру кысаларында Балтач муниципаль районы территориясендә 2025 елның I яртыеллыгына гомуми торак мәйданының бер квадрат метрының бәясен 55 834 сум 00 тиен күләмендә расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтына (http://baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) йөкләргә.

Җитәкче А.Ф. Хәйретдинов